КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.11.2021 г.Казань № 297-П

Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында урнашкан ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектлары территориясенең чикләрен һәм файдалану режимын раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы “Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре” карары нигезендә боерам:

1. Бу боерыкка 1 кушымта нигезендә, Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында урнашкан ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектлары территориясенең чикләрен расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

2. Бу боерыкка 2 кушымта нигезендә, Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында урнашкан ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектлары территориясеннән файдалану режимын расларга.

3. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә ачыкланган мәдәни мирас объектының чикләре турындагы мәгълүматларны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертүне тәэмин итәргә.

4. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Комитет рәисе урынбасары Н.В.Прохоровага йөкләргә.

Председатель И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының «02» 12.2021 елның
297-П боерыгына 2 кушымта

Татарстан Республикасының Спас муницапаль районында урнашкан ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектлары территориясеннән файдалану режимы

1. Татарстан Республикасы, Спас районы, Ржавец авылының төньяк-көнбатыш очында урнашкан «Ржавец авылы I»;

2. Татарстан Республикасы, Спас районы, Ржавец авылы үзәгеннән 1,1 чакрым төньяк-көнбатыш очында урнашкан «Ржавец авылы IV»;

2. Татарстан Республикасы, Спас районы, Ржавец авылы үзәгеннән төньяк-төньяк-көнбатышка 4,2 чакрымда, элеккеге Болгар авылы чиркәвеннән 6,97 чакрым төньяк-көнчыгышта урнашкан «Усть-Вихлян комплексы»;

Археологик мирас объектлары урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында” 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон) билгеләнгән тәртиптә, 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, ачыкланган археологик мирас объектларының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектларга керүен тәэмин итү шартларында урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.

Ачыкланган археологик мирас объектлары урнашкан су объектын яисә аның өлешен куллануның аерым режимы ачыкланган археологик мирас объектларының сакланышын тәэмин итү, шулай ук 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның күрсәтелгән объектларга керүен һәм археологик кыр эшләрен уздыруны тәэмин итү шартларында Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.